РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ
БОЛЬШЕШИНАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422054, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422054, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru


РЕШЕНИЕ КАРАР
23.09.2019 №14

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының
2012 нче елның 15 нче гыйнварендә кабул ителгән
1 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге
мәнфәгатьләрендә ачык сервитутларны билгеләү
һәм туктату тәртибе" турында
карарына үзгәрешләр кертү турында»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 26.02.2019 елгы №127 "Татарстан Республикасы мәнфәгатләрендә ачык сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибенә үзгәрешләр кертү турында" карарына туры китереп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының"Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге мәнфәгатьләрендә ачык сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибен раслау турында"15.01.2012 елгы 1нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге мәнфәгатьләрендә ачык сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны "Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге белән каралган очраклардан тыш" сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 3 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

"3. Ачык сервитут:

1) җир участогы аша үтү яки бару, шул исәптән гражданнарның гомуми кулланылыштагы су объектлары яки аның яр буе полосаларына ирекле керүе максатында;

2) җир участогына межалау билгеләрен, дәүләт геодезик челтәрләренең геодезик пунктларын, гравиметрик пунктлар, нивелир пунктлар һәм аларга якын килү юлларын урнаштыру;

3) җир участогында дренаж эшләре уздыру;

4) су объектларыннан су ресурсларын алганда;

5) җир участогы аша авыл хуҗалыгы хайваннарын куып алып чыкканда;
6) җир участогында билгеләнгән шартларда җирле шартларга һәм гореф-гадәтләргә срогы туры килгәндә, печән чабу, авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү;
7) җир кишәрлеген ау һәм балык тоту, аквакультура( балык үрчетү) максатларында кулланган очракларда билгеләнә".
1.3. 15 пунктның беренче абзацында "җир участогының кадастр паспортына" сүзләрен "күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына" сүзләре белән алыштырырга;
1.4. 16 пунктның өченче абзацында "күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрына" сүзләрен "күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына" сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/shinar адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов